**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет муниципального образования «поселок городского типа Актюбинский» Азнакаевского муниципального района**

ул. Губкина, д. 24, п.г.т.
Актюбинский, Азнакаевский
муниципальный район, 423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты**

Губкин урамы, 24 йорт, Актүбә ш.т.п.,
Азнакай муниципаль районы, 423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» август 2021 ел № 64

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 5 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын әзерләүгә керешергә.

2. Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын әзерләү буенча эшләрне үткәрү тәртибен һәм срокларын билгеләргә.

3. Әлеге карарны Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.И. Мөхәмәтҗанов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына кушымта
«26» август 2021 ел № 64

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районыиың "Актүбә шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын әзерләү буенча эшләр үткәрү тәртибе һәм сроклары**

| № | Генераль план проектын әзерләү буенча эшләр үткәрү тәртибе | Эшләрне башкару вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Генераль план проектын әзерләү эшләрен оештыру. | III квартал 2021 ел. |
| 2. | Генераль план проектының беренче редакциясен әзерләү һәм килештерү. | IV квартал 2021 ел, I – II кварталы 2022 ел. |
| 3. | Генераль план проектының ахыргы редакциясен әзерләү, фикер алышу һәм килештерү. | III – IV кварталы 2022 ел. |
| 3.1. | Генераль план проектын килештерү, бастырып чыгару. | |
| 3.2. | Иҗтимагый фикер алышулар һәм ачык тыңлаулар үткәрү. | |
| 3.3. | Генераль план проектын раслау. | |
| 3.4. | Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23 статьясындагы 5, 6 өлешләре нигезендә Генераль план проекты нигезләмәләрен бастырып чыгару. | |
| 3.5. | Генераль план проектын Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына җибәрү. | |